ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

КАРАР

2020 ел, 5 октябрь №7

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башлыгы, район Башлыгы урынбасары, контроль-хисап палатасы Рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 658 номерлы карары, 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карарына таянып Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары рәисләренең айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында карарларына таянып Татастан Республикасы Апас муниципаль район Советы карар бирә:

1.«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башлыгы, район Башлыгы урынбасары, Контроль-хисап палатасы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турындагы» нигезләмәгә **(**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2018 елның 27 апрелендәге 142 номерлы карарына 1 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«2.Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләменә бермәбер исәпләнә. Шул ук вакытта авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләме 11 498 сум тәшкил итә»;

«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгы, башлык урынбасары, контроль-хисап палатасы рәисе, муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү турында» нигезләмәнең 2 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә.

Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында Интернет телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Апас муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе Р. В. Нурмиевага йөкләргә.

4.Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Апас муниципаль районы
Башлыгы
Апас муниципаль районы
Советы рәисе **Р.Ф. Хисамутдинов**

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы Советының
2020 елның 5октябрендәге
7номерлы карарына кушымта

«Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы Башлыгының
Башлык урынбасарының,
Контроль-хисап палатасы Рәисенең
һәм муниципаль хезмәткәрләрнең
хезмәте өчен түләү» турындагы
2020 елның «____»_____
___номерлы карарына 2нче кушымта

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башлыгының,
Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башлык урынбасары,
Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Контроль-хисап палатасы
Рәисенең акчалата түләү күләмнәре

Вазифа атамасы	Акчалата түләү күләме (сум)
Район Башлыгы	30442
Башлык урынбасары	27398
Контроль-хисап палатасы рәисе	27398